ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Молодежная, д.13, д. Средняя
Корса, Арский муниципальный район,
422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур, 13 нче йорт, Урта Курса
авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

« 29 » сентябрь 2016 ел №12

**«Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентында җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобиль йөртүгә, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 18 июлендәге 16162 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Салым кодексының 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы 333.33 маддәсенең 1 пунктындагы 111 пунктчасы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 18 июлендәге 1616г номерлы карары нигезендә Урта Курса авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирде:

1. Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 18 июлендәге 11 номерлы карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә җирле әһәмияттәге юллар буйлап тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча автомобиль йөртүгә, эре габаритлы йөкләр ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына «Урта Курса авыл җирлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Урта Курса авыл җирлеге карары белән расланган муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә уза торган маршрутлар буенча рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 бүлекнең 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт пошлинасы күләмнәре:<br>автомобиль юлы буйлап йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт чарасы хәрәкәтенә махсус рөхсәт биргән өчен (халыкара автомобиль ташуларны гамәлгә ашыручы транспорт чарасыннан тыш):<br>куркыныч йөкләр - 1300 сум;<br>авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы йөкләр - 1 600 сум | РФ НК 333.33 статьясының 1 пунктындагы 111 пунктчасы |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина